КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 12 август г.Казань № 675

Саба муниципаль районында җир кишәрлекләрен бер категориядән икенче категориягә күчерү турында

Россия Федерациясе Җир кодексы, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Җирләрне яки җир кишәрлекләрен бер категориядән икенче категориягә күчерү турында» 2004 елның 21 декабрендәге 172-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьядагы 1 өлешенең 9 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Саба муниципаль районында урнашкан, «Саба муниципаль районының Мичанское авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге милкендә булган 2,9524 гектар гомуми мәйданлы авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җир кишәрлекләрен бу карарга кушымта нигезендә кадастр саннары белән ритуаль эшчәнлек объектларын урнаштыру максатларында сәнәгать, энергетика, транспорт, элемтә, радиотапшыру, телевидение, мәгълүмат, космик эшчәнлекне тәэмин итү җирләре, оборона җирләре, куркынычсызлык һәм башка махсус әһәмияттәге җирләр категориясенә күчеререргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 12 август, 675 нче
карарына кушымта

Сәнәгать, энергетика, транспорт, элемтә, радиотапшыру, телевидение, мәгълүмат, космик эшчәнлекне тәэмин итү җирләре, оборона җирләре, куркынычсызлык һәм башка махсус әһәмияттәге җирләр категориясенә күчерелә торган җир кишәрлекләре
исемлеге

| Җир кишәрлегенең кадастр саны | Мәйданы, гектар |
|---|---|
| 16:35:120503:1 | 1,5357 |
| 16:35:120601:5 | 1,4167 |
| Барлыгы | 2,9524. |

_______________________________